# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең Зуево торак пунктында

« 03» декабрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең Зуево торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ**:

1.Зуево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган (I һәм II төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, раслаучы документлар булганда, ирекле халык дружинасы әгъзаларыннан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш) 2020 елда 250 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Зуево авылында суүткәргечләрне төзекләндерү.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //agryz.tatarstan.ru игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы А.Н. ЛАЗАРЕВ